КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 16 июль г.Казань № 572

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 20 ноябрь, 887 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының район үзәкләреннән 11 километрданераграк урнашкан Татарстан Республикасының ерак булган һәм халык аз яши торган авыл пунктларына беренче дәрәҗәдәге кирәкле товарларны илтүгә бәйле булган кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының район үзәкләреннән 11 километрданераграк урнашкан Татарстан Республикасының ерак булган һәм халык аз яши торган авыл пунктларына беренче дәрәҗәдәге кирәкле товарларны илтүгә бәйле булган кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 20 ноябрь, 887 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 30 июль, 615 нче, 2019 ел, 28 декабрь, 1228 нче, 2020 ел, 30 октябрь, 972 нче

карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасының район үзәкләреннән 11 километрдан ераграк урнашкан Татарстан Республикасының ерак булган һәм халык аз яши торган авыл пунктларына беренче дәрәҗәдәге кирәкле товарларны илтүгә бәйле булган кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә, 9 пунктның беренче абзацында «рәвеше Министрлык тарафыннан раслана торган» сүзләрен «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма нигезендә» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин